**СОВЕТ**
**НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**СОВЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“31” октябрь 2019 ел** **№130**

**“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында”**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Яңа Кенәр” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 15 номерлы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында” Нигезләмәне раслау хакында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Фәхретдинов

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ